**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы**

**Байлангар авыл җирлеге Башлыгы**

**карары**

**2020 елның 13 ноябре** **N17**

**«Кукмара муниципаль районы Байлангар авыл җирлеге Байлангар авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын үткәрүне билгеләү турында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Кукмара муниципаль районы Байлангар авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә

КАРАР БИРӘМ:

1. 2020 елның 25 ноябренә 10 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Байлангар авыл җирлеге Байлангар авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Байлангар авылы, Совет урамы, 6 нчы йорт адресы буенча урнашкан Байлангар авылы клубы бинасында үткәрергә.

2. 2020 елның 25 ноябренә 14 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Байлангар авыл җирлеге Байлангар авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Байлангар авылы, Совет урамы, 6 нчы йорт адресы буенча урнашкан Байлангар авылы клубы бинасында үткәрергә.

3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: «I төркем инвалидлар, укучылар һәм көндезге уку формасы буенча укучы студентлар (курсантлар), 18 яшькә кадәрге 3 һәм аннан күбрәк баласы булган әниләр, 80 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк затлардан кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Байлангар авыл җирлеге Байлангар авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2021 елда үзара салымны 500 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

- Байлангар авылында Ф. Заһидуллин, Мәктәп урамы юлларына вак таш җәю; проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру; (сатып алу, ташу, вак таш җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү);
- Байлангар авылында, вак таш җәеп, Ф. Заһидуллин, Г. Тукай урамнарында юллардагы чокырларны ямау; проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру;
- Совет урамы, 27 нче торак йорт һәм Совет урамы, 69 нчы торак йорт янында Нурминкә елгасы аша салынган җәяүлеләр күперен төзекләндерү;
- Байлангар авылы урамнарын яктырту өчен светодиод лампалар һәм махсус җиһазлар сатып алу;

- Байлангар авылы зиратына материал сатып алу һәм коймалар урнаштыру; проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру;

- Байлангар авылы урам юл челтәрен карап тоту;

- Байлангар авылында артезиан скважиналары өчен насослар сатып алу;

- Байлангар авылында артезиан скважиналары өчен насослар сатып алу;

- кышкы чорда кабер казу өчен генератор һәм вата торган чүкеч сатып алу;

- Байлангар авылында Совет урамына тышкы видеокүзәтү камералары сатып алу һәм урнаштыру?»

«РИЗА» «КАРШЫ»

5. Гражданнар җыенын үткәрү өчен торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген территориаль билге буенча (урамнар буенча) бүләргә.

6. Гражданнар җыенын оештыручы итеп, Байлангар авыл Башкарма комитетын билгеләргә.

7. Әлеге карарны кабул ителгән көннән соң 5 көн эчендә мәгълүмат стендларында һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

8. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Авыл җирлеге Башлыгы И. Х. Миңнегалиев

БАЙЛАНГАРСКИЙ СЕЛЬСКИЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КУКМОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РТ • ТР КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАЙЛАНГАР АВЫЛ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ • ОГРН 1091675010462 ИНН 1623008401